# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**

19 ноябрь 2024 ел № 2

20.03.2025 № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Россия Федерациясенең Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы "Яңа Мәлкән авыл җирлеге" Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү торак пунктында халык җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. Минзәлә муниципаль районы Яңа Мәлкән авыл җирлегенең Дусай-Кичү авылында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертергә (1 һәм 2 төркем инвалидлардан, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Россия Армиясе сафларына хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, МХОда катнашучы гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларынан, МХОда катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (вафат булган) гражданнарның гаилә әгъзаларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш).
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Дусай-Кичү торак пункты чикләрендә Җәлил урамындагы гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту - авыл эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, килешү буенча түләү).

3.Халык җыены нәтиҗәләрен Яңа Мәлкән авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән http://menzelinsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә .

Халык җыенында рәислек итүче,
Яңа Мәлкән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Нәҗметдинов З.И.